**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ АЙМАН АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ**

423739, Иске Айман авылы,
Яна ур., 5а нчы йорт. Тел.3-44-52

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ СТАРОАЙМАНОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423739, село Старое Айманово,
ул. Новая ,дом 5а,
Тел. 3-44-52

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«16» ноябрь 2024 ел №2

### Актаныш муниципаль районының Иске Айман авыл җирлегенең Колын авылында узара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының нәтиҗәләре турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 ноябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2024 елның 15 ноябрендә Иске Айман авыл җирлеге Колын авылында узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: “2025 елда Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Колын авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылардан, Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация кысаларында мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус хәрби операция зонасында контракт буенча хәрби хезмәт узучы хәрби хезмәткәрләрдән, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан тыш, җирлектә 700 сум күләмендә үзара салым акчасы җыеп, түбәндәге эшләрне башкарырга:

1. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (урам юлларын тоту);
2. Традицион күмү урыннарын ремонтлау, киртәләр урнаштыру, төзекләндерү (зиратларны карап тоту);
3. Су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан тәэмин итүче башка инженер корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, халыкка су ташу һәм бирү (су үткәрү челтәрен карап тоту, ремонтлау).

«риза» 42
«каршы»
«тоткарланучылар»-

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 84 граждан, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 42 граждан кертелгән.

Ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

“риза” позициясе өчен 42 граждан тавыш бирде;
"каршы" позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде.

"тоткарландылар" позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнары җыены **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Иске Айман авыл җирлегендә гражданнар җыенын узган дип таныргa, гражданнар җыенының нәтиҗәләре дөрес.
2. «2025 елда үзара салым кертүгә Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Иске Айман авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән,1 төркем инвалидлардан, хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылардан, Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация кысаларында мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус хәрби операция зонасында контракт буенча хәрби хезмәт узучы хәрби хезмәткәрләрдән, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан тыш, җирлектә 700 сум күләмендә үзара салым акчасы җыеп, түбәндәге эшләрне башкарырга:

1. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (урам юлларын тоту);
2. Традицион күмү урыннарын ремонтлау, киртәләр урнаштыру, төзекләндерү (зиратларны карап тоту);
3. Су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан тәэмин итүче башка инженер корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, халыкка су ташу һәм бирү (су үткәрү челтәрен карап тоту, ремонтлау).

3. Әлеге карарны Иске Айман авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга - http://aktanysh.tatar.ru

Иске Айман авыл җирлеге башлыгы М.Р.Әхмәтханов